С Ы Й Ф А Т

Предметның билгесен белдереп,нинди? кайсы? кайдагы? сорауларына җавап бирүче мөстәкыйль сүз төркеме

Тышта ак кар ява

Бу җөмләдә карның ак төстә булуы әйтелә. Бу җөмләдә без карның тик ак икәнен генә беләбез. Һәм бу сыйфатның **гади дәрәҗәсе** була

Ак, зәңгәр, матур, яшел, сары, чибәр, зур, кечкенә

Беренче шар икенчесеннән кызылрак

Бу җөмләдә сыйфат шарның кызылрак икәнен хәбәр итә, ягъни аны икенче шар белән чагыштыра.

Гади дәрәҗә+ рак, - рәк кушымчасы= чагыштыру дәрәҗәсе

Кызылрак, зәңгәррәк, олырак, кечкенәрәк, матуррак, озынрак

Бу алма кып – кызыл булып пешкән

Бу җөмләдә сыйфат алманың нык кызыл булуын, артыгыннан бигрәк кызаруын күрсәтә.

1. Көчәйткеч кисәкчә(кып-,кап-зәп-, сап-,ямь-)+ гади дәрәҗә= артыклык дәрәҗәсе

2. Иң, үтә,дөм, җете кисәкчәләре + гади дәрәҗә = артыклык дәрәҗәсе

3. Сыйфатларның кабатлануы = артыклык дәрәҗәсе

Сап-сары,кап-кара, зәп-зәңгәр, ямь-яшел.

Иң матур, үтә чибәр, җете кызыл, дөм сукыр.

Кызылның кызылы, матурның матуры, сарының сарысы.

Күлнең суы зәңгәрсу төстә иде

Бу җөмләдә сыйфат күлнең зәңгәрдән ачыграк булуын күрсәтә, кимлек билгесен өсти.

Гади дәрәҗә+ -су, -гылт, -кылт, -келт, -кылтым, - келтем, -елҗем, -сыл кушымчалары = кимлек дәрәҗәсе

Зәңгәрсу, кызгылт, ачкылт, яшькелт, ачкылтым, төчкелтем, күгелҗем, аксыл

ТӘМАМ!
Игътибарыгыз өчен
ЗУР РӘХМӘТ!!!